Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

# К А Р А Р

2020 елның 25 марты № 44/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына яңа редакциядә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча 2020 нче елның 3 февралендәге Бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 16 августындагы 28/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең «Этика һәм хезмәт тәртибе кодексы нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык» V бүлегенең 28 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«28» пункты номерын «29» номерга алмаштырырга»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«29. Муниципаль хезмәткәрләргә Кодекс нигезләмәләрен бозу факты Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаны биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында каралырга тиеш, һәм, Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәткәргә юридик җаваплылык чараларын куллануга китерә.».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына муниципаль хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.М. Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров